*Баширова И.Б. (ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, Казань)*

# ИСКЕ ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫНА ГАРӘП ВӘ ФАРСЫ ТЕЛЕНЕҢ ТӘЭСИРЕ

**Аннотация:** Бу мәкаләдә, X1 гасыр гомумтөркидән башлап, XII-XX йөзнең беренче чирегенә кадәр гарәп графикасында язылып килә торган иске татар теленең язма нормасын, ягъни традиция булып килә торган тотрыклылыгын саклаганы хәлдә, шул ук вакытта, билгеле бер үзгәрешләре белән, Болгар чорында, Алтын Урда дәүләтендә, Казан ханлыгында, Русия дәүләтенең Идел-Урал буе регионындагы язма әсәрләрдә дәвам ителүе, әлеге юнәлештә аңа гарәп һәм фарсы теленең тәэсире – вазыйфасы күзәтелә.

**Төп сүзләр:** төрки тел, иске татар теле, гарәп графикасы, җанлысөйләмә тел, әдәби язма тел, норма һәм вариантлылык.

## Influence of Arabic and Persian on the use of the ancient Tatar language

**Abstract:** In this article development specifications of Old Literature Tatar language written standards are reviewed, which continued the traditions of General Turk written language and which were reflected in various genres or styles of artworks created during the times of Volga State of Bulgar, Golden Horde, Kingdom of Kazan and Russian State (circa middle of XIVth century in Volga region).

**Key words:** the Turkish language, the ancient Tatar language, Arabic script, colloquial, literary language, language standart and varieties.

Кереш. Мөселман югары уку йортларында ныклы белем бирү юнәлешендә, татар теле, татар язма әдәби теле һәм гарәп-фарсы телләренең үзара мөнәсәбәтен аңлау һәм аңлату белүнең зарурлыгы күренә. Хәзерге татар телендә әлеге мәсьәләгә, татар лексикасын өйрәнү барышында игътибар ителә. Гарәп һәм фарсы алынмалары унөч төркемгә бүлеп карала (Сафиуллина, 1999, б.59-66). Әмма әлеге мөнәсәбәтнең татар теле өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуы, барлык тулылыгы белән иске татар телендә чагылыш таба.

Иске татар теле дигән термин, XI гасырдан гарәп графикасындагы гомумтөрки нигездә, XII-XIII гасырлардан – XX йөзнең беренче чирегенә кадәр, язма традицияне дәвам итеп, болгар-татар нигездә, ягъни мең еллар буена, гарәп графикасы белән языла торган әдәби тел истә тотыла. Беренче мәртәбә бу атаманы «Нур» газетасында «Әдәби телебез нә делдер?». дип бара торган фикер алышуда, гарәп алынмалары мул файдаланыла торган әдәби әсәрнең теле мәгънәсендә, газетаның мөхәррире ахунд хәзрәтләре Гатаулла Баязитов куллана («Нур», 1905, №11). Төрки гаиләдә гасырлар буена эзлекле рәвештә дәвам ителә торган язма телләрнең берсе буларак, иске татар теленең башка мәгънәләре булуы да игътибарны җәеп итә. Бу юнәлештә, төрки атамасына күчкәнче, җанлы сөйләмә тел белән язма әдәби тел төшенчәләренең үзара бәйләнешенә кыскача гына булса да игътибар итү сорала.

1. Җанлы-сөйләмә тел кешеләрнең үзара аралашуын, гаилә-төбәк даирәсендә тормыш-көнкүрешне алып бару, тирә-юньне танып белү, аң-фикерне формалаштырып тәкъбир итү, хис-кичерешләргә тәэсир итү һ.б. кебек вазыйфаларны башкара, ягъни үзенең төп функциясендә кулланыла. Телнең бу мөмкинлекләренең чын мәгънәсендә тулаем реальләшүе, телнең язма формасы белән тормышка ашырыла: тирә-юньне танып-белүдән туган аң-күзаллау-фикер, язмада теркәлеп калса гына башка укучыга, башка буыннарга да җиткерелә, төшенчәләр формалаша, фәнни әдәбият, уку-укыту әсбаплары языла; хис–кичерешләр дә талантлы шагыйрьнең шигъри тезмә юлларында, яисә матур әдәбиятның чәчмә формаларында укучыга эстетик тәэсир итәрлек сәнгатьле чаралар белән, әдәби сөйләм булып күпчелеккә барып җитә; үз кул астындагы халыкны, үзе теләгәнчә билгеле бер тәртиптә тоту өчен кирәк булган дәүләт-хөкүмәт карар-указлары да язуга төшерелеп игъ-

лан ителә; әлеге эшчәнлекне яклый-хуплый торган сәяси оешмалар, аларның матбугаты да фикерләрен укучыга язма рәвештә тәкъдим итә. Нәтиҗәдә, язма әдәби тел, җәмгыять даирәсендәге, дәүләти-сәяси-иҗтимагый тормышны алып бару юнәлешендәге, киң кырлы вазыйфа үти торган күп функцияле катлаулы көчкә әверелә. Телнең бу вазыйфаларын үтәү өчен, дәүләт-идарә тарафыннан уңай-кирәк дип саналып, озын-озак гасырларга сузылган мөмкинлекләре ачылган булса, аның традициясе-дәвамчанлыгы формалаша, ягъни фикерне хәбәр итүдә тел берәмлекләрен дөрес файдаланылуын күрсәтә торган низам-тәртибе, билгеле бер дәрәҗәдә ныгыган әдәби нормасы барлыкка килә. Дәверләр буена эзлекле рәвештә дәвам ителә торган иске язулы телләр, традиция булып килә торган әдәби норманың төрле ысуллар белән баетылуы нәтиҗәсендәге вариантлары белән кулланылышта хәрәкәт итә. Әлеге мәсьәләләрне тикшерүнең теоретик нигезе – әдәби телнең үсеш этапларын, ягъни аерым стильләрендә ничек итеп файдаланылуын күзалларга мөмкинлек бирә, практик яктан – шул үсешне яшәтә торган вариантларның табигате һәм вазыйфасы тулырак билгеләнелә. Бу мәсьәләләр соңгы бер-ике ел эчендә дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» (Казан, 2014) һәм «Татар әдәби теле тарихы»на (Казан,2015) нигезләнеп анализлана. Бу мәкаләнең максаты: мең еллар буена дәвам итеп килә торган төрки–болгар–иске татар телендә язма норманың, а) традицион тотрыклыгы саклануын, ә) төрле региональ төбәк телләре нигезендә барлыкка килә торган норма вариантлары белән берлектә дәвам ителешен, әлеге юнәлештә гарәп һәм фарсы теленең тәэсирен–вазыйфасының тоткан урынын күзаллау.

2.Төрки-татар теле – борынгы (иске) язулы телләрнең берсе. Төрки терминының, төрки гаиләдәге кавемнәрнең исем–шәрифе, аларның сөйләмә һәм язма телләренең атамасы булуы, М.Кашгариның «Диване лөгатет-төрек» сүзлегендә тәфсилләп аңлатылуы мәгълүм (466/1072-1074). Бу атамалар хәзерге вакытта да шул ук мәгънәләре белән кулланыла. «Языки мира:Тюркские языки» дигән энциклопедик басмада, төрки гаиләдә 15 борынгы һәм хәзерге вакытта яши торган 39 халыкның, язмачылык тарихы V-VI,VIII-IX, X-XII йөзләрдә башланып, XII-XIII гасырдан язма истәлегенең язылу датасы мәгълүм булган иске язулы (старописьменные) телләргә

ия дигәндә, әзербайҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк телләре белән рәттән, татар теле дә истә тотыла (Языки мира..., 1997, с. 358). Этносның барлыкка килүен билгеле бер датага бәйләп караган кебек (Гумилев, 1993, с.26), әдәби телнең язылa башлавын белдерә торган чыганакны да конкрет бер датага бәйләп карарга кирәк булу игътибар үзәгенә куела. Әдәби истәлек язылган төбәкне(дәүләтне, төп шәһәрен), төгәл күрсәтү нигезендә, аның графикасын, язма тел белән шул региондагы диалект-сөйләмә тел һәм авыз иҗаты үзенчәлегенең үзара мөнәсәбәтен билгеләргә, гасырларга бүлеп караганда, истәлекләр язылa торган әдәби телнең эзлекле булып килә торган язма традициясе булуын күзалларга мөмкин була (Языки мира...1977, б.35-46). Махсус әдәбиятта аңлатылганча, иске язулы телләр әдәби нормага нигезләнә, норманың традициясе дәвам ителә. Язма норма дигәндә, график билгеләр системасы һәм аларның графо–орфографик тәртибе истә тотыла (Ахманова, 1969, с. 533). Теләсә кайсы төрки телнең, шул исәптән татар теленең, язма әдәби теле һәм аның тарихы тикшерелгәндә әлеге фикерләр гомумнәзари итеп кабул ителә.

Татар теле иске язулы телләрнең берсе дигәндә, V-VII гасырларда угыз-уйгыр-кыпчак кабилә телләренә нигезләнеп килә торган язма традициясе дәвам ителүе, XII-XIII гасырларда Идел буе Болгар дәүләтендә, гарәп графикасы белән каберташларга штамп–текстлар язылу, Төркестан (Яса) әдәби үзәгендә язма әдәбият үсеш алу, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы иҗат ителү(1233 елның 12 маенда тәмамлана) истә тотыла. Идел буе төрки-болгар (Болгар төркисе) дигән язма тел гамәлгә куела, борынгы татар әдәби теленең барлыкка килү җирлеге дип тәгаенләргә мөмкин булу аңлашыла (Татар әдәби теле тарихы, 2015, б.32-36). XIII гасырның икенче яртысы – XV йөзнең беренче яртысына кадәр яшәүдә булган, Алтын Урда дәүләтенең язма теле, «...Идел– Болгар дәүләтендәге төрки–болгар, ягъни карахани-уйгыр (харәзем-төрки)нигезгә көньяк-угыз һәм төньяк–кыпчак (Идел буе-татар) элементлары кушылган әдәби телнең дәвамы була(Тенишев, 1987, с.135-137). Берничә мәдәни Үзәк барлыкка килә. Һәр ун ел саен, эчтәлегенең нинди булуына карап, дини-дидактик һәм дөньяви-мәхәббәт темаларына бүленә торган күләмле тезмә һәм чәчмә әсәрләр иҗат ителүе, төрле сүзлекләр төзелүе мәгълүм (Нуриева, 2004, с.

3; Исламов,2014,б.379-392). Бу дәүләтләрдә кулланыла торган әдәби телне галимнәр төрлечә атый, шул төшенчәләрне берләштереп, Алтан Урда язма телен, Идел буендагы болгар–кыпчак–татар әдәби теле дип әйтә алабыз. Болгар дигәндә,әдәби телнең төрки нигездәге традициясе, кыпчак–татар дигәндә, җирле сөйләмә телнең һәм авыз иҗаты әсәрләренең тәэсире, татар дигәндә,хәзерге телебезгә мөнәсәбәте барлыгын аңлап, бу телне иске татар теле дип әйтергә мөмкин булуы аңлашыла (Татар әдәби теле…, 2015,б.37-41). ХУ гасыр урталарында Казан ханлыгы яшәеш ала. Сөйләмә теле – болгар-татар халкының өч төрле (урта, көнбатыш, көнчыгыш) этник төркеменең сөйләше чагылыш таба торган диалектлар теле (Зәкиев, 2008,б.240-241). Әлеге тел әдәбиләштерелеп «Идегәй», «Чура батыр»,»Алпамыш»,»Түләк» һ.б. дастаннар язмага төшерелә. Алтын Урданың таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килсә дә, яшәп китүе, шул империянең бер олысы булган Болгар мәдәни–икътисади тормышының, язма традициянең дәвамын тәшкил итә. Матур әдәбият стилендә, тезмә жанрлар үстерелә (Татар әдәбияты…, 2014, т. 2, б. 123). Әднаш Хафизның 40 фасылга бүленгән»Сиражел–колуб» чәчмә әсәре языла (1554). Казан ханлыгында, Алтын Урда чорындагы кебек үк, рәсми хатлар-битекләр, дәүләт башындагы монархлар тарафыннан түбәнрәк дәрәҗәле шәхесләргә бирелә торган әмер-фәрман-ярлыклар язышу дәвам итә, ягъни рәсми-канцелярия һәм дипломатия стиле үсеш ала, төрле фәннәргә караган хезмәтләр языла. Казан ханлыгында иҗат ителгән әсәрләрнең телен авторларның барысы, үзләреннән алдагы торадицияне дәвам итеп, төрки телдә язам дип белдерә («Нуры содур» поэмасында бу фикер ун мәртәбә кабатлана). Хәзерге әдәбиятчы галимнәр, бернинди искәрмә ясамыйча, әлеге әдәбиятны татар телендә язылган дип белдерә. Болай дп әйткәндә, хәзерге татар теле истә тотылганга күрә, әдәби телне исемләүнең кабул ителгән тәртибе, ягъни традициясе булуы юкка чыгарыла, әсәр авторының фикере инкяр ителә. Шуңа күрә телче галимнәр Болгар төркисе, Алтын Урда төркисе белән рәттән, Казан төркисе, Идел буе төркисе дип исемләүне дәвам итәләр (Фасеев,1966,с.812). Махсус әдәбиятта бу дәвер әдәби теле Урал-Идел төркисе, иске татар төркисе, иске татар әдәби теле, иске язулы татар теле, Башкортстан һәмКазахстандагы иске татар язма теле дип тә

атала (Языки мира.., 1997, с. 126). Идел буе дигәндә, язма телнең урынчалыгы, иске татар теле дигәндә, традицион төркинең, билгеле бер регионда, дәүләттә яшәүче халыкның сөйләмә һәм авыз иҗаты формалары белән баетылып дәвам ителеше күз уңында тотыла. Әлеге үзенчәлек чынбарлыкка туры килгәнгә күрә, XV гасыр һәм аннан соң гарәп графикасында язылган әсәрләрнең телен, төгәл терминлаштырып, иске татар телендә язылган дип әйтергә кирәк була. Хәзерге вакытта, иске татар теле төшенчәсе, гарәп графикасында язылган барлык чорларга караган әдәби тел дигән мәгънәдә дә файдаланыла. Иске язудагы истәлекләр, филологик юнәлештә фәнни тикшерелсә һәм укытылса, алар классик телләр дип атала (Ахманова, 1969, с. 196). Иске татар телендә язылган истәлекләр, татар һәм башка төрки телләрдә тикшерелгәнгә һәм укытылганга күрә, бу чор иске татар телен классик иске татар теле дип әйтергә мөмкин була. Шул ук вакытта иске татар телен, XIII-XV,XVI-XVII, XVIII-XIX гасырлардагы катлаулы иҗтимагый-сәяси, рухани-мәдәни хәлләрне төрле жанр–стильләрдәге текстларда теркәп калдыра торган төп чара буларак, татар милли әдәби теленең барлык тармакларына хас булган язма норманың формалашу нигезе дип санарга тиеш булабыз (Татар грамматикасы, 1998, т. 1, б. 49).

Язма норма дип әйтә башлаганда, иске татар теленең, язма традициясе сакланып дәвам ителә торган төрки телләрнең берсе буларак, Йосыф Хаҗ Баласагунлының «Котадгу Белек» (462/1069-1070) әсәреннән, ягъни X1 гасырдан башлап – XX йөзнең беренче чирегенә кадәр (латинга күчкәнче), 922 елда төркиболгарлар тарафыннан рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү белән бергә кулланыла башлаган гарәп графикасы белән язылуын искә төшерергә кирәк була. Язма норма графоорфографик тәртип нигезендә аңлатыла. Гарәп теле, фарсы теле, аларның сарыф вә нәхүе, имля-орфографиясе мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укытыла, ятлатыла, Иляһи өрфия белән уратылып, аңга сеңдерелә. Ипи өстенә Коръән куярга ярый, Аллаһы Тәгаләдән иңгән Коръән өстенә ипи куярга ярамый дип, язма телне, китапны хөрмәт итәргә кирәк дигән әдәп–тәртипкә өйрәтелә. Рухани – дини тәгълимат-идеология теле буларак гамәлгә куелган язма телнең, әлифбасы белән бергә, сүз, сүзформа, сүзтезмәләре,дини штамп–шәкелләре, грамматик төзелешенә караган үзенчәлекләре һ.б. тел

берәмлекләре иркен файдаланыла. Язма әдәбиятта югары стиль төшенчәсен барлыкка китерә, халыкның сөйләмә теленә, авыз иҗатына үтеп кереп, сөйләүченең укымышлы булуына ишарә итә. Әлеге мәсьәләгә мөнәсәбәт белдереп, академик М.И. Мәхмүтов болай дип яза: «…Татар халкының милли культурасы, әлбәттә, аның үз этник мәдәниятенә нигезләнеп үсеш ала, әмма аңа гарәп–иран цивилизациясе дә көчле йогынты ясый. Бу – мөселман дине, дини фәлсәфә, китап һәм мәгърифәт, бай шәрекъ әдәбияты. Дин һәм этник культура бергә үрелеп, аларның синкретик берлеге көндәлек ритуалларда, гореф–гадәт, телдә ныгып, башка язмыштагы халыкларның аңыннан, диненнән, фикерләү үзенчәлегеннән үзгә булган, татар халкының үзенә генә хас булган билгеле бер фикерләү тибын, иҗтимагый аңын барлыкка китерде» (Махмутов, 1992, с. 45). Шулай булуга карамастан, Л. Җәләй ассызыклаганча, гарәп теле бер вакытта да, татар халкының тулаем әдәби теле вазыйфасын үтәү дәрәҗәсенә күтәрелми.

3. Иске татар телендә традиция буларак дәвам ителә торган язма норманың тотрыклануын төрки һәм гарәп теле мөнәсәбәенә нигезләнеп карарга мөмкин булу.

Гарәп теленең татар халкында, тулаем әдәби тел булып кулланылмавы хакында, татар филологларына «Татар әдәби теле тарихы» курсы буенча укый торган лекциясендә, функциональ телләр турында дип, профессор Л.Җәләй мондый искәрмә ясый: «…Кайбер халыклар әдәби тел вазыйфасында икенче халык телен йөрткәннәр, сөйләштә үз телләре булса да. Кайбер Европа халыкларында борынгы латин теле шундый тел була. Татар теле тарихында гарәп теле әдәби тел функциясен үтәми, аерым галимнәр китапларын гарәпчә язсалар да. Намаз гарәпчә укыла, әмма дини китаплар күбрәк татар телендә дә язылган, динне халыкка тизрәк җиткерү өчен…»(Җәләй, Лекция. Кульъязма, 1958). Әмма гарәп һәм фарсы алынмалары, хосусый терминнары белән, үзенең тарихы, табигате һәм вазыйфасы булган дини-дидактика дигән стиле булып формалаша. Табигате дигәндә – һәр диннең үзенә хас булган ысуллары, кешеләргә дини –рухани тәгълимат бирү өчен барлыкка килгәен, аң–акыл тарафыннан кабул ителгән, төрки–татар әдәби телендә, озын гасырлар буена файдаланылып, яктыртылып килүе нәтиҗәсендә, махсус калыплашкан сөйләм тибы булуы истә тотыла. Вазыйфасы – дини-рухани

тәрбия бирү, ягъни кешене рухи һәм физик яктан сәламәт тоту, аның иманын-ышанычын саклау, күңеленә изгелек сеңдерү, адәм балаларының үзара мөнәсәбәте – намуслылыкка, әдәп–әхлакка, сабырлык–түземлелеккә нигезләнергә тиешлекне аңлату–вәгазьләү. Дини–дидактика стиленең үз эчендәге жанр-төрләре дигәндә, халкыбыз тормышының барлык яклары белән бәйле булган эшчәнлек төрләрен күз алдында тотарга тиеш булабыз. Мәсәлән, бала тугач исем кушу, үсеп җиткәч, никях укыту, көндәлек ритуалларны үтәү, үлем килгәч, мөселман дине шартларына туры китереп, соңгы юлга озату һ.б.Әлеге эшчәнлек, үзенең хосусый атамалары белән җанлы сөйләмә телдә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә, язма әдәбиятта чагылыш таба. Дини йолалар татар әдәби теленең аерым бер стиле булып өйрәнелмәгән. Телдән файдалануда башка стильләрдән үзгә: гарәп телендәге өзекләр тәрҗемә ителеп, шәрехләнеп аңлатылырга тиеш. Димәк, бу стильне өйрәнүче кешегә гарәп телен, иске татар һәм хәзерге татар әдәби телен камил белергә кирәк була.

Әлеге катлаулы мәсьәләне өйрәнергә керешкәнче, гарәп вә фарсы теленең иске татар теленә булган тәэсирен төгәлерәк күзалларга кирәклек күренә. «Татар әдәби теле тарих»ын язу барышында, әлеге бәйләнеш–мөнәсәбәтнең объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында фәнни – дөрес итеп аңлатылмаганлыгы мәгълүм булды. Тарих – язмыш кушуы шулай булгандыр, XX гасырның 10 нчы елларыннан башлап, татар исеменә каршы куелып, төрки атамасы «...әллә нинди бер хыялый түреклек» дип (Вәлиди, 1912, 2007, б.199), «...без татармы-түгелме мәсьәләсенә аптырап калулдары сәбәбендән, әсәрләрен ниндидер томанлы, ике мәгънәле бер исем белән атыйлар»дип (Ибраһимов, 1915, 2007, б.20), гаилә-нигез теле булган төрки атамасының асыл мәгънәсе шик астына алына. 20 нче еллардан башлап гарәп теле халыкка аңлашылмый торган баткаклык дип ышандырырга тырышыла. «Безнең төрек–татар телләренең әдәби тел булып эшләнүләре аларның истикъляль(бәйсезлеге) һәм гавамлашуы өчен уңайсыз булган әхваль эчендә, гарәп һәм фарсы һөҗүме астында барлыкка килде....Татар теленең гарәп һәм фарсы баткаклыгыннан котылып, мөстәкыйль бер әдәби тел рәвешендә эшләнүе фәкать 1905 нче елдан соң гына барлыкка килде. Шулай итеп, әле ул һәнүз 17 яшьлек кыздыр», – дип

белдерелә (Вәлиди, 1922, 2007, б. 154). Г.Ибраһимов хезмәтләрендә:»...бездә бер әдәби ел ясалды. Бу – ярым чыгтай, чирек госманлы калыбына сугылган, чобар төрки теле иде....бу икегә башка гарәпчә, фарсыча сүзләргә зур ирек бирелгән...»,–дип киңәйтелә барды (1915, 1922, 1924, 2007, б.16-17, 33, 34). Алга таба бу фикерләр: «...власть пролетариат кулына күчү белән, татар әдәби телендә дә чын мәгънәсе белән революция ясала, халыкка аңлашылмый һәм татар хезмәт массасының хәзерге культура үсеше өчен һичбер әһәмияте булмаган гарәп һәм фарсы сүзләре татар әдәби теленнән сөрелә...»,–дип тагын да кискенләштерелде (Бәдигый, 1930, 2008, б. 172; Сәгъди, 1939, б. 108-112)».... Бер яктан, әле «төрки тел» дип аталган борынгы феодализм чорының корама «китап теле» дәвам итсә, икенче яктан, пантюркистлар Волга буе татарларына да, әдәби тел итеп төрек телен көчләп тагарга маташтылар», –дип (Рамазанов, 1954, б. 60, 77, 91) һ.б. Күп кенә галимнәрнең хезмәтләре дә шул юнәлештә барды, гомумтөрки белән гарәп вә фарсы алынмалары һәм аларның татар әдәби теленә булган мөнәсәбәте безнең бу-ынга, асылда, халык аңламый торган корама-чобар дип кире төсмердә аңлатылды. Мең еллар буена иске татар телендәге әдәбиятның төп коралы булган чараның уңай ягы булганмы? дигән сорау туу табигый хәл.

XII йөздән – XIX йөзнең ахырына кадәр иҗат итүче төрки–татар авторларның барысы да диярлек, V-VII г.гомумтөркидән, XI гасыр «Котадгу Белек»тән килә торган традицияне дәвам итеп, әсәрләренең төрки телдә язылуына, ягъни гарәп яисә фарсы телендә язылмаганлыгына, басым ясап, кат–кат искәртә баралар. Төрки телендә язылган әсәрләре белән генә халык хәтерендә сакланачагы өмет ителә. Шуның белән бергә, авторның кайсы укучыны күздә тотып, аңа әйтергә теләгән фикеренең нинди булуына карап, төрки телдәге берәмлекләрнең махсус сайланып, гарәп һәм фарсы алынмаларының ни дәрәҗәдә файдаланылуы нәтиҗәсендә, төрки тел дигән күренешнең бер генә төрле булмаганлыгы күренә. (Татар әдәби..., 2015). Әлеге аерымлану «Котадгу Белек» һәм «Диван-и хикмәт»ләрдән башлана. Йосыф Хаҗ Баласагунлының төрки дөньяда ислам идеологиясен аңлату һәм тарату максаты күздә тотылган беренче мәшһүр әсәрендә гарәп һәм фарсы алынмалары мул кулланыла, Орхон язмаларыннан килгән региональ төрки арха-

ик сүз һәм сүзформалар итēлә (Благова,1977, с.99-100). Әхмәд Ясәвинең (1091-1166) «Диван-и хикмәт» ләрендә аять белән хәдиснең мәгънәсен аңлату өчен, төрки теленең муафикъ булуы белдерелә, ягъни алынмаларны куллану билгеле бер дәрәҗәдә азая, таралып яшәгән төркиләрнең күбесе өчен уртак булган сөйләмә сүз һәм сүзформалары әдәбиләштерелгән халыкчан язма әдәби тел белән языла. Әлеге ике төрдәге (стильдәге) төркине файдалану, авторларның максатына ярашкан хәлдә, аерым урынчалыкның сөйләмә формалары белән төрлечә баетыла барып, гасырлар буена дәвам ителә. Нәтиҗәдә, гарәп һәм фарсы алынмаларының кулланылу дәрәҗәсенә карап, иске татар телен ике төрдә (стильдә) хәрәкәт итүен билгеләргә мөмкин була. Нәкъ менә шушы нигездә иске татар теленә хас булган язма нормны объектив күзалларга мөмкинлек ачыла.

Мәгълүм булганча, иске татар телендә гарәп һәм фарсы алынмалары үз чыганак теле кагыйдәсе буенча языла. Бу турыда Җ.Вәлиди мондый мәгълүмат бирә: «Безнең хәзер истигъмаль кыла торган хәрефләребез гарәп хәрефләре булып, моның асылы –дөньядагы язуларның күбесенең асылы булган финика хәрефләредер. Бу хәрефләрнең гарәптә истигъмаль кылына торганы 29 булып, алар түбәндәгеләр»,– дип санап чыга һәм дәвам итә: «Бу алфавиттагы хәрефләрнең бер өлешендә күрсәтелгән авазлары татар телендә булмаса да һәм алар арасында татар авазларына кирәкле кайбер хәрефләр табылмаса да, ул алфавит безнең татарчага шул көенчә, ягъни һичбер үзгәртелмичә кабул ителгән; чөнки ул вакытта татар теленең табигатен тикшереп, шуңа муафикъ кагыйдәләр төзү эшләре бөтенләй булмау өстенә, бу алфавит безгә дин белән берлектә килеп кергән. Динне ислях кылу хакында сүз булмаган кебек, шул диннең бер кисәге, коралы дип танылган хәрефләрне төзәтү хакында да уйлаучы, әлбәттә, булмаган...» (Вәлиди, 1919, 2007, б. 55). Әлеге фикер Ф.С. Фасеев хезмәтендә дә искәртелә: «... Письменность тюрки основана на арабской графической базе с его слоговым–консонантным принципом и потому с самого начала не было ориентирована на точное следованию звучанию,...арабские, персидские, чагатайские, османские заимствования сохраняли, как правило, орфографию своих исходных письменных языков (Фасеев, 1982, б.49). Аңлашылганча, гарәп вә фарсы алынмаларын үз чыга-

нак телендәгечә язу таләп ителә. Әлеге үзенчәлек иске татар әдәби теленең нормасын билгеләү өчен дә җирлек була. Мәгълүм булганча, XIII-XIV йөзләрдә «Кыйссаи-Йосыф», Рабгузиның «Кыйссасел әнбия», XV-XVI г. Казан ханлыгында Өмми Камал, Максудиның «Могҗизнамә», Мөһәммәдъяр поэмалары, XVI г. ахыры – XVII йөздә Суфи Аллаһиярның «Сөбател гаҗизин», XVII йөз ахыры – XVIII йөздә Батыршаның «Гарызнамәсе», Т. Ялчыголның «Рисаләи Газизә...», Г.Утыз Имәнинең башлангыч, XIX йөзнең беренче яртысына кадәр тулы иҗаты, шул ук вакытларда Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәкинең тезмә әсәрләре гарәп-фарсы алынмалары белән туендырылган аристократ төркидә иҗат ителә. Бу әсәрләрнең тел тукымасының яртысыннан күбесен, катгый рәвештә үз чыганак теле кагыйдәсен саклап язылa торган гарәп вә фарсы алынмалары тәшкил итә. Димәк, текстның яртысыннан күбесе ныклы нормага нигезләнә була. Төрки-татар сүзләренең язылышында да унификацияләнү, кыскалык саклануга карамастан, сүзнең башында, уртасында һәм ахырында сузык авазларны билгеләүдә, тартык авазларны файдалануда билгеле бер тәртип урнаша «Татар әдәби теле тарихы»ның Графикага багышланган 1 томында әлеге мәсьәлә җентекләп тикшерелде. Җанлы-сөйләмә сүз һәм сүзформалар әдәбиләштерелеп (сайлап алына, мәгънәсе катлауландырыла, кабатлану ешлыгы төрлечә була һ.б.) языла торган Җырау-шагыйрьләрнең тезмә әсәрләре, Мәүлә Колый иҗаты, «Иляһи бәетләр», Баһави һәм Г.Кандалый иҗатында, XIX г. икенче яртысында да кабул ителгән язма норма дәвам ителә. Әлеге ике төрле традицион-нигез сакланганы хәлдә (Г. Тукайның башлангыч чоры иҗаты), һәр чордагы әдәби телнең кулланылышында, үзенә хас булган яңалыгы барлыкка килә. X1X гасырның ахырларында әдәби телнең угызлашкан төре активлаша. Һәр дәвернең иҗтимагый-сәяси шартларына, әсәр языла торган төбәктә яшәүчеләрнең җанлы сөйләмә теле һәм халык авыз иҗаты үзенчәлекләре белән бәйләнешенә, шул чорда яшәүче авторларның белеме-мәктәбе, нинди тема күтәрүләре, әдәби телнең кайсы жанр-стилендә, кайсы укучыны күздә тотып иҗат итүләренә, гомумән, максатлары нинди булуга карап һ.б. мәсьәләләргә бәйләнешмөнәсәбәттә, әдәби телдә барлыкка килгән яңалыклар, язма норманың дәвам ителешенә дә, вариантларның табигатенә һәм вазыйфасына да, хәтта төрки

тел дигән төшенчәнең нинди мәгънә белән кулланылышына да тәэсир итәләр. Әлеге катлаулы мәсьәләләр әдәби тел тарихын язганда, эзлекле анализлау нәтиҗәсендә ачыла бардылар. Бу мәгълүматларга нигезләнеп, алга таба «Иске татар әдәби телендә дини-дидактика стиле» дигән теманы тикшерә башларга була.

Йомгак. «Татар әдәби теленең тарихы» хезмәтен язу барышында, әдәби телне эзлеклелектә, ныклы системада тикшерүгә таянып, бүгенге көнгә кадәр дәвам итеп килә торган, иске татар теле корама-чобар булган, «...единого письменно–литературного языка начиная с XШ до первой четверти XX вв. не было...» (История татарского..., 2003, аннотация) дигән фикерләрнең объектив дөреслеккә туры килмәве, бу мәсьәләләрне иске татар һәм гарәп вә фарсы телләренең мөнәсәбәте нигезендә аңлатырга мөмкин булуы күренде. Алга таба, татар әдәби теленең җиде стиленең берсе булган. Дини-дидактика стилен тәфсилләп тикшерергә кирәк булачак.

Әдәбият:


1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. – 1969. – 606 с.
2. Бәдигый Хуҗа:тел галиме, фольклорчы, педагог. – Казан, 2008.– Б.157-189.
3. Благова Г.Ф. О методике изучения морфологии средневековых тюркских поэтических текстов//Вопросы языкознания. – 1977. – №3.
4. Вәлиди Ж.Сайланма хезмәтләр: әдәби тел,грамматика, диалектология һәм лексикография мәсьәләләре.– Казан: Мәгариф, 2007. – 271 б.
5. Гумилев Л.Н. Древние тюрки. – М.,1993. – 526 с.
6. Зәкиев М.З.Татар халкы тарихы: (этник тамырлары, оешуы һәм киләчәге). – Казан, 2008. – 544 б.
7. Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият. Сайланма хезмәтләр.–Казан: Мәгариф, – 2007. – 239 б.
8. Махмутов М.И. К вопросу об изменениях в лексике татарского языка //Төркиләрнең телләре,рухи мәдәниятләре һәм тарихлары:традицияләр һәм заман:1т. – Казан, 1992.